ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 104 от «04» 04 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 5 октябрендә кабул ителгән
325 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташу белән идарә итү һәм җайга салу системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы чикләрендә билгеләнгән транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 5 октябрендә кабул ителгән 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 Кушымтасыны 4.1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Субсидияләр бирә торган бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) һәм муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан тикшерүләр башкаруга ризалык бирә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып ччыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма көмитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов